**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 2 октябрь | № 734

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарында норматив документлар әзерләү эшчәнлеген камилләштерү буенча өстәмә чаралар турында» 2006 ел, 31 август, 441 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарында норматив документлар әзерләү эшчәнлеген камилләштерү буенча өстәмә чаралар турында» 2006 ел, 31 август, 441 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Рспубликасын социаль-икътисади үстерү программасы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары белән» сүзләренә алмаштырырга, текстта «тапшырырга» сүзе алдыннан «1 октябрьдән соңга калмыйча,» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы министрлыклары һәм дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген планлаштыруның сыйфатын күтәрергә;»;

пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«федераль законнар белән эшләү һәм бастырып чыгару (кабул итү) каралган норматив хокукый актларны үз вакытында эшләүне һәм бастырып чыгаруны (кабул итүне) тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы законнары бастырып чыгарылган (кабул ителгән) көннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма

органнарының норматив хокукый актларын бастырып чыгаруны (кабул итүне) һәм Татарстан Республикасы законнары белән эшләү һәм бастырып чыгару (кабул итү) каралган норматив хокукый актлар проектларын билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне тәэмин итәргә;

хисап кварталыннан соң килүче айның 1 көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы законнары белән эшләү һәм бастырып чыгару (кабул итү) каралган норматив хокукый актларны эшләү барышы һәм күздә тотылган кабул итү вакытлары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.»;

4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тапшырган Татарстан Республикасы законнары белән эшләү һәм бастырып чыгару (кабул итү) каралган норматив хокукый актларны эшләү барышы һәм күздә тотылган кабул итү вакытлары турында мәгълүматны квартал саен гомумиләштерергә һәм, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 көненнән дә соңга калмыйча, гомумиләштерелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.»;

6 пунктта «Интернет» халыкара компьютер челтәрендәге сайтта» сүләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында» сүзләренә алмаштырырга;

7 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\734.docx